ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» февраля 2026 ел № 84

Әгерҗе муниципаль районында алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм бетерү буенча ведомствоара район комиссиясе составын раслау турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, шәхси белешмәләрнең үзгәрүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм бетерү буенча ведомствоара район комиссиясенең кушымтада бирелгән составын расларга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм кисәтү буенча ведомствоара район комиссиясе составын раслау турында" 03.05.2024 елның 135 номерлы;
- "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм кисәтү буенча ведомствоара район комиссиясе составын раслау турында" 19.01.2021 елның 9 номерлы;
- "Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм кисәтү буенча ведомствоара район комиссиясенең яңа составын раслау турында" 19.12.2016 елның 603 номерлы.

3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәриповка йокләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының 06.02.2026
елның 24 номерлы карары белән
расланды

## Әгерҗе муниципаль районында алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм бетерү буенча ведомствоара район комиссиясе составы

1. Шәрипов Рөстәм Рәшитович – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе;
2. Заитова Аида Салиховна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый үсеш бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары;
3. Гаврилова Диана Сергеевна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый үсеш бүлеге баш белгече, комиссия секретаре;

Комиссия әгъзалары:

1. Вафина Гөлшат Тависовна – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чаллы территориаль органы башлыгы (килешү буенча);
2. Хуҗәхмәтов Тимур Рәсимович - Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча);
3. Абзалиева Эльза Равильевна – бүлек җитәкчесе - Татарстан Республикасы буенча УФССП суд приставларының Әгерҗе район бүлеге өлкән суд приставы (килешү буенча);
4. Овчинников Эдуард Вильевич – «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча);
5. Гыйсмәтуллина Рәисә Тәлгатовна - Татарстан Республикасы буенча Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең Алабуга, Әгерҗе, Менделеевск районнарында территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча);
6. Хәкимова Эльвира Рәисовна - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторы мөдире;
7. Абдрахманов Радик Фәридович - Менделеевск МРСО Россия Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча җитәкчесе (килешү буенча);
8. Коротков Игорь Викторович – «Алкоторг» ҖЧҖ Әгерҗе шәһәре һәм Әгерҗе районы буенча сәүдә вәкиле (килешү буенча);
9. Шәрипова Лилия Ринатовна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча);
10. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының авыл җирлекләре Башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча).